# Визитка

# Пошалым варислары






**Саттарова Энҗе,Хөснетдинов Ранил,Рәхимҗанова Айгөл, Абдуллин Миннур,Зиннатуллина Дилә.**

Без тарихта эзлебез

# Девиз:











**Их, Пошалым чанасы,**
**Җәйләр җитсә арбасы.**
**Авылыбыз даны җырда,**
**Тарихларда калсачы...**

***Айгөл Рәхимҗанова***

# Туган авылым- Пошалым



Яз килүгә, туган авылым
Яшеллеккә күмелә.
Һәрбер өе,сукмаклары
Бигрәк якын күңелгә.







Авылны икегә бүлеп,
Саф сулы инеш ага,
Балык тота, су коена
Биредә бала-чага.

Су буйларын ямьләндерә
Өянкеләр, камышлар.
Күңелләргә шатлык тула
Онытыла сагышлар.





Еракларга сузылганнар
Болыны- басулары;
Йөрәкләргә шифа була
Чишмәләрнең сулары

Рөстәм абый күк җырчылар
Үсә безнең якларда;
Горурлык хисләре арта
Ул җырлаган чакларда

Җәен-шау чәчәккә төренеп, ә кышын- сихри ап-ак карга бизәнгән матур белем сараебызны без бик яратабыз, данын еракларга тарату өстендә армый- талмый эшлибез



